ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КОРМАШ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ЖИТӘКЧЕСЕ

423733, Иске Кормаш авылы,
Үзәк ур.,
29 нчы йорт. Тел.5-04-10

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ
СТАРОКУРМАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
423733, село Старое Курмашево,
ул. Центральная,дом 29, Тел. 5-04-10

КАРАР
от «18» июня 2019 года

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
№ 15

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге башкарма комитетынын 11.01.2019ел. № 1 "Запастагы гражданнарны хәрби исәпкә алуны оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 1996 елның 31 маеннан "Оборона турындагы", 1998 елның 28 мартыннан "Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт" турындагы, 1997 елның 26 феарленнән "Мобилизацион әзерлек һәм Россия Федерациясендә мобилизация" турындагы федераль законнарны үтәү максатыннан һәм 27.11.2006 елның 719 санлы "Хәрби хезмәт нигезләмәсе турында", Россия Федерациясе Кораллы Көчләре запастагы гражданнарын , запастагы федераль башкарма хакимият органнарының һәм дәүләт хакимияте органнарында, авыл җирлеге органнарында һәм оешмаларда эшләүче гражданнарны броньлау буенча төп нигезләмәләр" турында Россия Федерациясе хөкүмәте карарын, үтәү максатларында Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Кормаш авыл җирлеге башкарма комитетының 11.01.2019 ел 1 санлы «Запастагы гражданнарны хәрби исәпкә алуны оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Исеме

1.1.7. 111 бүлегенең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

- «3.2. җирле үзидарә органы үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган территориясендә яшәүче гражданнарның яки вакытлыча яшәүче (3 айдан артык вакытка) беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашырырга »;

1.2. Нигезләмәнең 111 бүлегенең 3.8 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

- «3.8. Ел саен хәрби комиссариатка 15 яшькә җиткән ир - атлар һәм 16 яшькә җиткән ир-атлар һәм 16 яшькә җиткән гражданнар исемлекләрен, ә 1 ноябрьгә кадәр-киләсе елда хәрби исәпкә беренчел куелырга тиешле ир-атлар исемлеген хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмә белән билгеләнгән форма буенча тапшырырга кирәк;»;

1.3. Карарның 2 нче кушымтасының 17 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- «17. Ел саен хәрби комиссариатка 15 яшькә җиткән ир - атлар һәм 16 яшькә җиткән ир-атлар һәм 16 яшькә җиткән гражданнар исемлекләрен, ә 1 ноябрьгә кадәр-киләсе елда хәрби исәпкә беренчел куелырга тиешле ир-атлар исемлеген хәрби исәпкә алу турындагы Нигезләмә белән билгеләнгән форма буенча тапшырырга кирәк;»;

1.4. Карарның 2 нче кушымтасының 19 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

- «19. Чираттагы чакырылыш башланыр алдыннан барлык призывникларга да характеристикалар бирергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Иске Кормаш авыл җирлеге хәбәрләре бүлегендә урнаштырырга.

3.Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Иске Кормаш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Кашбразиев И.Ә